Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

3 июль, 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки "Кояшкай" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен бетерү турында фикер алышу өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясендә урнашкан Күки авылы гражданнары җыелышын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законы, 2012 елның 29 декабрендәге "Россия Федерациясендә мәгариф турында" 273-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, 2013 елның 23 июлендәге "Мәгариф турында" 68-ЗРТ номерлы Татарстан Республикася законының 13 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Күки авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки "Кояшкай" муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен бетерү турында фикер алышу өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге территориясендә урнашкан Күки авылы гражданнары җыелышын (алга таба - гражданнар җыелышы) 2023 елның 5 июленә 14 сәгать 00 минутка түбәндәге адрес буенча урнашкан: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Мәктәп урамы, 20 йорт, муниципаль бюджет гомуми белем бирүче "Күки төп гомуми белем бирү мәктәбе" бинасына билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәэмин итүне йөкләргә:

2.1. гражданнар җыелышын әзерләү һәм үткәрү;

2.2. гражданнар җыелышы нәтиҗәләре буенча беркетмә әзерләү;

2.3. гражданнар җыелышы нәтиҗәләрен, куелган тәртип буенча, бер ай срок эчендә халыкка җиткерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районы Күки авыл җирлегенең  Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күки авылы, Мәктәп урамы, 20 йорт, адресы буенча урнашкан  махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль районы
Күки  авыл җирлеге башлыгы A.М.Бәдретдинов